КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 август г.Казань № 1047

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 9 июль, 554 нче карары белән расланган Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 июль, 554 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 13 сентябрь, 864 нче; 2022 ел, 12 гыйнвар, 8 нче; 2022 ел, 30 июль, 738 нче; 2023 ел, 2 февраль, 85 нче; 2023 ел, 4 март, 206 нчы; 2023 ел, 31 июль, 909 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен дәүләт милкендәге яки муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен юридик затларга, сатулар үткәрмичә, арендага бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктның 9 пунктчасында:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«50 проценттан артык акцияләре (устав капиталындагы өлешләре) хуҗалык җәмгыятенә караган, 100 процент акцияләре (устав капиталындагы өлешләре) Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек милкендә булган, аерылып чыккан җәмгыять булып торган юридик заттан үтенечнамә кергән

очракта, үз акчасы булуын раслау мондый хуҗалык җәмгыятенең үз акчасы белән рөхсәт ителә. Раслана торган үз акчасының күләме юридик зат – проект инициаторының бизнес-планы буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 процентын йә бирелә торган җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) агымдагы кадастр кыйммәтеннән ким булмаган күләмдә тәшкил итәргә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Проектны тормышка ашыруның (объектны урнаштыруның) башка очракларында, юридик зат – проект инициаторының раслана торган үз акчасы күләме инвестицияләр күләменең кимендә 30 проценты күләмендә йә бирелә торган җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) агымдагы кадастр кыйммәтеннән ким булмаган күләмдә билгеләнә;»;

3.2 пунктның 9 пунктчасында:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«50 проценттан артык акцияләре (устав капиталындагы өлешләре) хуҗалык җәмгыятенә караган, 100 процент акцияләре (устав капиталындагы өлешләре) Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек милкендә булган, аерылып чыккан җәмгыять булып торган юридик заттан үтенечнамә кергән очракта, үз акчасы булуын раслау мондый хуҗалык җәмгыятенең үз акчасы белән рөхсәт ителә. Раслана торган үз акчасының күләме юридик зат – проект инициаторының бизнес-планы буенча инвестицияләр күләменең кимендә 30 процентын йә бирелә торган җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) агымдагы кадастр кыйммәтеннән ким булмаган күләмдә тәшкил итәргә тиеш.»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Проектны тормышка ашыруның (объектны урнаштыруның) башка очракларында, юридик зат – проект инициаторының раслана торган үз акчасы күләме инвестицияләр күләменең кимендә 30 проценты күләмендә йә бирелә торган җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) агымдагы кадастр кыйммәтеннән ким булмаган күләмдә билгеләнә;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин